СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы карары**

**01 ноябрь 2024 ел** **№ 8**

**Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең Иске Чүриле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Иске Чүриле авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең Иске Чүриле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 21 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка халык җыенының 1 нче этабын билгеләргә. Адресы: Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт.

2. Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең Иске Чүриле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2024 елның 22 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка халык җыенының 2 нче этабын билгеләргә. Адресы: Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 нче этап: Яңа урамы, Яшел урамы халкы.

2 нче этап: Матросов урамы, Мәктәп урамы халкы.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Иске Чүриле территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү

һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа урам, Җирле әһәмияткә ия булган машина юлына вак таш җәеп, юл полотносын ремонлау, Иске Чүриле авылы Яшел урам);

- янгын куркынычсызлыгың беренчел чараларын тәэмин итү (1 данә янгын гидранты сатып алу һәм Матросова урамына урнаштыру);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторына отвал сатып алу)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

5. Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең Иске Чүриле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы Иске Чүриле авылы, Яңа урам, 52 йорт адресы буенча, ТР, Арча районы Иске Чүриле авылы, Мәктәп урам, 34 йорт адресы буенча,интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Чүриле авыл
җирлеге башлыгы Р.Р. Рамазанов

СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СТАРОЧУРИЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ИНН1609012646